СОВЕТ КРАСНОГОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Мира, д.11А, п.с-за “Мамадышский”,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422165

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫЗЫЛ ТАУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мира ур., 11А нче йорт, “Мамадыш” совхозы поселогы, Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422165

тел.(факс): (85563) 3-91-14; e-mail: KrGor.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
«19» февраля 2020 г.

Карар
№3-50

Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 11 апрелендәге 1-30 санлы карары белән расланган «ТатарстанРеспубликасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен Төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон,«Россия Федерациясендә инвалидларнысоциаль яклау турында»Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»һәм«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләркүрсәтүне оештыру турында»Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешенең 16 пунктынүз көчен югалткан дип тану хакында»2019 елның 18 июлендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон,«Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законынигезендә,«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Мамадышмуниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Кызыл Тау авыл җирлеге Советының 2018 елның 11 апрелендәге 1-33 номерлы карары (2018 елның 17 сентябрендәге 2-37 номерлы редакциясендә) белән расланган «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясенТөзекләндерүкагыйдәләренәтүбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«29.Гомуми файдаланудагы барлык парковкаларда, шулисәптәнсоциаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы объектлары (торак, җәмәгать һәм җитештерүбиналары, төзелеш һәм корылмалар, шулисәптән физкультура-спорт оешмалары, мәдәният оешмалары һәм башка оешмалар урнашкан урыннарны да кертеп), ял урыннарында,I, II төркеминвалидлары идарә иткән транспорт чараларын һәм мондый инвалидларны һәм (яки) инвалид балаларныйөртүче транспорт чараларын түләүсез кую өченкимендә 10 процент

урын (әммаберурыннан да ким түгел) бүлепбирелә.III төркеминвалидлары арасыннан булган гражданнарга әлеге өлешнормалары Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тарала.Күрсәтелгән транспорт чараларында «Инвалид» танып-белүбилгесекуелырга һәм бу транспорт чаралары турында мәгълүмат инвалидларның Федераль реестрына кертелгән булырга тиеш.»

2.Әлеге карарны Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенеңмахсусмәгълүматистендларында, Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати-коммуникациончелтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарныңүтәлешенконтрольдәтотуны Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгынайөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Гыйззәтулина В.А /